МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.07.2016 г. Казань №_под-1342/16

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» гранты турында» 2016 елның 12 июлендәге 1342/16 номерлы боерыгы

Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм итү өчен, боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» грантын булдырырга.

2. Китерелгәннәрне расларга:

2.1. «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» гранты турында нигезләмәне.

2.2. 2016 елга «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» гранты чараларын тормышка ашыруның календарь планын (алга таба – Чаралар).

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының структур бүлекләре җитәкчеләренә һәм Чараны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларга әлеге боерыкның 2.2 пункты белән расланган планның үтәлешен тәэмин итәргә.

4. 2016 елның 18 июленә кадәр Гомумбелем бирү идарәсенә (Т.Т. Федорова) бәйгедә катнашырга теләгәннәрне конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру һәм грант тапшыру өчен Эксперт комиссиясе составын раслауга кертергә.

5. Татарстан Республикасының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автономияле учреждениесенә (Г.Д. Зарипова) «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» грантына оештыру-методик булышуны тәэмин итәргә.

6. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г.Ф. Гатиятуллина) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының җыелма сметасы хисабыннан Чараны финанслауны тәэмин итәргә.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Премьер-министры Э.Н. Фәттахов

урынбасары - министр

ТР Юстиция министрлыгында 2016 елның 1 августында теркәлде.

Теркәлү номеры 3454

«Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» гранты турында нигезләмә
(Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 12 июлендәге 1342/16 номерлы боерыгы белән расланды)

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» гранты (алга таба - Грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән булдырыла.

1.2. Грант Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына, аларда олимпиада клублары булдыру һәм оештыру максатыннан, ярдәм итүгә йөз тота.

Грантны булдыручы (Грант бирүче) һәм Грант алучы Грант катнашучылары булып тора.

Грантны булдыручы (Грант бирүче) – грантлар бирү буенча вәкаләтләр башкаручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы.

Грант алучы – Татарстан Республикасының гомумбелем бирү оешмасы яки Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, базасында олимпиада клубы булдырылучы сәләтле балалар өчен интернаты булган, һәм конкурста сайлап алуны узган оешма.

1 алып, 13гә кадәр урын алган Грант алучыларга, сәләтле балалар үстерүгә һәм аларга ярдәм итүгә, аларны төрле дәрәҗәдәге интеллектуаль конкурсларда һәм ярышларда катнашырга мотивацияләүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен, бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк грант була, аның күләме:

1,5 млн.сум бер үк вакытта гомумбелем бирү оешмасында яшәү белән төп гомумбелем бирү программасын үзләштерүче 200 кадәр тәрбияләнүчесе булган интернатка (алга таба –интернатта тәрбияләнүчесе);

1,8 млн.сум 200 алып, 230 кадәр интернатта тәрбияләнүчесе булган;

2,1 млн.сум 230 алып, 300 кадәр интернатта тәрбияләнүчесе булган;

2,2 млн. сум 300 алып, 360 кадәр интернатта тәрбияләнүчесе булган;

2,3 млн. сум 360 алып, 500 кадәр интернатта тәрбияләнүчесе булган.

1.3. Грант ияләрен сайлап алу халыкка ачык характерда һәм ачык булу принциплары нигезендә уздырыла.

1.4. Олимпиада клубы Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмасы базасында булдырыла, һәм сәләтле балаларның төрле яклап үсешен ачыклау һәм аларга ярдәм итү, аларны төрле дәрәҗәдә интеллектуаль конкурсларда һәм ярышларда катнашырга мотивацияләү максатыннан, эшли.

1.5. Олимпиада клубы – белем, техника, мәдәниятнең төрле өлкәләрендә тагын да тирәнрәк уңышларга ирешергә омтылучы интернатта тәрбияләнүчеләрнең ирекле берләшмәсе.

## 2. Конкурста катаншырга гариза тапшыру

2.1. Грант алырга теләүчегә гаризаны 2016 елның 12 августына кадәр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автономияле учреждениесе рәсми сайтының «Чаралар» бүлегендә, «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» битендә бирергә кирәк.

2.2. Грант алуга конкурс Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә уздырыла.

2.3. Грант бирүче 10 көн алдан Грант бирүченең рәсми сайтында боерыкны урныштыру юлы белән конкурс уздыру турында игълан итә.

2.4. «Республика олимпиада үзәге» ДАУ, конкурста катнашуга электрон рәвештә гаризалар тапшыру өчен, оператор булып тора.

2.5. Грант алырга теләүче, 2016 елның 12 августыннан соң гариза тапшырган очракта, конкурса катнашу хокукыннан мәхрүм кала.

## 3. Конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Конкурс ике этапта уздырыла:

читтән торып – мәгълүмат материалларын тапшыру;

урынга килеп – Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмасында олимпиада клубы эшчәнлеге проектын яклау.

Гаризада раслаучы документларны беркетеп, сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмасының уңышлары турында мәгълүмат бирергә кирәк.

Сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмасы уңышларының гомуми күрсәткече конкурсның Грант алырга теләүчеләрне читтән торып сайлап алу критерийлары булып тора, ул түбәндәгеләрне исәпкә алып формалаша:

1) базасында республика, Бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларда югары нәтиҗәләр күрсәткән олимпиада клублары булдырылачак, сәләтле балалар өчен

интернаты булган гомумбелем бирү оешмалары рейтингы (алга таба – рейтинг);

2) үзләренең методик эшләнмәләре булу.

3.2. Рейтинг түбәндәге күрсәткечләр нигезендә төзелә:

соңгы өч ел үсешендә интернатта тәрбияләнүчеләрнең Бөтенроссия олимпиадасында катнашу нәтиҗәләре (төбәк һәм йомгаклау этаплары);

соңгы өч ел үсешендә интернатта тәрбияләнүчеләрнең укучыларның республика олимпиадасында катнашу нәтиҗәләре;

соңгы өч ел үсешендә интернатта тәрбияләнүчеләрнең укучыларның халыкара олимпиадасында катнашу нәтиҗәләре;

3.3. Рейтинг балларны кушу юлы белән формалаша. Баллар түбәндәге тәртип буенча куела:

1 балл – укучыларның Бөтенроссия олимпиадасының яки республика олимпиадасының төбәк этабында һәрбер призер өчен;

3 балл – укучыларның Бөтенроссия олимпиадасының яки республика олимпиадасының төбәк этабында һәрбер җиңүче өчен;

5 балл – укучыларның Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында һәр призер өчен;

7 балл – укучыларның Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында һәр җиңүче өчен;

10 балл – укучыларның халыка олимпиадасында һәр катнашучы өчен.

3.4. Сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмасының эшчәнлек нәтиҗәләре күрсәткечләре буенча алынган баллар кушыла. Рейтингта гомумбелем бирү оешмалары оешма эшчәнлеге нәтиҗәләренең суммар күрсәткече буенча баллар кимү тәртибендә урнаша.

3.5. Килеп катнашу этабы проект яклау формасында (кәгазь һәм электрон йөртүчедә) уздырыла. Проект тарафыннан Олимпиада клубы эшенең эчтәлеге һәм формасы, максаты һәм бурычларны, проект идеясен билгеләп (проектның идеясе 1-3 җөмләдә ачылырга тиеш), төп чараларны, көтелгән нәтиҗәләрне, календарь планын тасвирлап, ачыла (5 биттән артмый).

Проектны яклау өчен вакыт 15 мин. артмый.

3.6. Грантның килеп катнашу этабында көч сынашыр өчен, читтән торып катнашкан этапның нәтиҗәләре буенча 1 алып, 16 кадәрге урыннарны яулаганнар чакырыла.

3.7. Түбәндәгеләр килеп катнашу этабының сайлап алу критерийлары булып тора:

Актуальлек, яңалык, гомумбелем бирү оешмасы алдына куелган бурычларны исәпкә алып, олимпиада клубы эшчәнлеге юнәлешләренең максатчан булуы;

проектны тормышка ашыру өчен кирәкле база булуы;

олимпиада клубының эшчәнлеген чынга ашыру нәтиҗәләрен фаразлау.

3.8. Конкурс материалларын бәяләү өчен, составына комиссия рәисе һәм 13 кешедән торган комиссия вәкилләре кергән эксперт комиссиясе булдырыла.

3.9. Эксперт комиссиясенең персональ составы Татарстан Республикасы

Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

3.10. Эксперт комиссиясе, ихтыяҗ туганда, конкурс материалларына өстәмә экспертиза уздыру өчен, белгечләр җәлеп итәргә хокуклы.

3.11. Эксперт комиссиясе вәкилләре конкурста катнашучы Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмасы җитәкчеләре һәм педагоглары була алмый.

3.12. Эксперт комиссиясе утырышлары кирәк булганда уздырыла, һәм аларда составының яртысыннан артыгы булса, алар хокуклы дип санала.

3.13. Эксперт комиссиясе вәкилләре 2016 елның 19 августына кадәр тапшырылган гаризаларны карыйлар, экспертиза нәтиҗәләре буенча эксперт йомгагын рәсмиләштерәләр һәм аларны Эксперт комиссиясе рәисенә тапшыралар.

3.14. Конкурсның читтән торып уздырылган этабы нәтиҗәләре буенча, Эксперт комиссиясе тарафыннан конкурсның килеп катнашу этабында чыгыш ясарга бертигез хокуклы булган (өстенлексез) Грант алырга теләүчеләрнең исемлеге формалаша.

Килеп катнашу этабын уздыру вакыты турында мәгълүмат әлеге этапка узган Грант алырга теләүчеләр исемлекләре белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм «Республика олимпиада үзәге» ДАУ сайтында урнаштырыла.

3.15. Конкурсның килеп катнашу этабында Эксперт комиссиясе:

әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән критерийлар нигезендә, Грант алырга теләүчеләрнең проектларын бәяли;

Эксперт комиссиясе вәкиле Грант алырга теләүчегә һәр критерий буенча 1 алып, 10 баллга кадәр куя, конкурс сайлап алуының һәр критерие буенча иң югары балл – 10 балл;

баллар эксперт кәгазьләренә кертелә, кушыла, Эксперт комиссиясе вәкиле имзасы белән рәсмиләштерелә һәм Эксперт комиссиясе рәисенә бирелә.

3.16. Эксперт комиссиясе 2016 елның 23 августына кадәр килеп катнашу этабы нәтиҗәләре буенча Грант алучылар исемлеген формалаштыра.

3.17. Грант алучылар исемлеге Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

3.18. Грант бирүче 2016 елның 24 августына кадәр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында «Укытучыларга грантлар» бүлегендә, «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмасына ярдәм» битендә Грант алучыларның расланган исемлеген урнаштыра.

## 4. Конкурсны финанслау

4.1. Грант оештыру һәм уздыру белән бәйле финанс чыгымнары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының җыелма сметасында каралган акчалар хисабына тормышка ашырыла.

4.2. Грантка нигез салучы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән субсидия алучы – муниципаль берәмлек арасында төзелә торган килешү субсидия күчерү өчен нигез булып тора.

## 5. Грант алучыларның хисапларын тапшыру тәртибе һәм вакыты

5.1. Грант алучылар Грант түләнгән елның алдагысында 1 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына олимпиада клубы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында фото (видео) материаллар һәм Грантлар түләүгә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан куллану турында материаллар белән хисаплар тапшыра.

5.2. Олимпиада клубы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисапта түбәндәге позицияләр чагыла:

олимпиада клубы алдына куелган максатларга ирешү;

олимпиада кулбында катнашучылар саны;

уздырылган чаралар саны;

олимпиада клубында катнашучыларның барлык дәрәҗәләрдәге олимпиадаларда, конкурсларда, турнирларда катнашу нәтиҗәлелеге;

5.3. Грантлар түбәндәге очракларда Грант алучылар хисап тапшырган мизгелдән алып, 60 көн дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш:

Грантлар бирү шартларын үтәмәү;

Грантларны максатчан кулланмау.

5.4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы грантларны максатчан куллануны контрольдә тота.

## «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» гранты чараларын тормышка ашыруның 2016 елга календарь планы (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 12 июлендәге 1342/16 номерлы боерыгы белән расланды)

| N т/п | Чара | Үтәү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | «Татарстан Республикасының сәләтле балалар өчен интернаты булган гомумбелем бирү оешмаларына ярдәм» грантын тормышка ашыру мәсьәләсе буенча оештыру комитеты киңәшмәсе (алга таба - Грант) | 2016 елның апреле | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестациялəве бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Муниципаль районнар башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) башлыклары белән киңәшмә | 2016 елның мае | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |
| 3. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында грант турында норматив-методик материалларны һәм реклама мәгълүматын урнаштыру | 2016 елның мае | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |
| 4. | Грант алырга теләүчеләрдән конкурста катнашуга документлар кабул итү, электрон теркәлү, конкурс документациясен карау | 2016 елның 12 августына кадәр | «Республика олимпиада үзәге» ДАУ, Эксперт комиссиясе |
| 5. | Эксперт комиссиясе утырышы, нәтиҗәләр ясау | 2016 елның 23 августына кадәр | «Республика олимпиада үзәге» ДАУ, Эксперт комиссиясе |
| 6. | Йомгаклау боерыгын бастыру | 2016 елның 24 августына кадәр | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |
| 7. | Грант алучыларга бер генә тапкыр бирелә торган грант түләүне оештыру | 2016 елның 20 декабренә кадәр | Бухгалтерия учеты һәм хисап бүлеге, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлеге |